**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2022 елның 18 ноябре 131№

Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның
12 апрелендәге 151 "Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында"
151 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Россия Федерациясе Генераль прокурорының 2007 елның 17 сентябрендәге "Прокуратура органнарының хокукый иҗат итү эшчәнлеге һәм дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне яхшырту турында" 144 номерлы боерыгы нигезендә, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 статьялары нигезендә, Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 12 апрелендәге "Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында" 151 номерлы карарына кушымта нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләрне хупларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А.Ф.Никошин

Әлки районы Советының  2022 елның
18 ноябрендәге 131 номерлы карарына
кушымта

**Әлки муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

4.2 пунктта «Җирлек» сүзен төшереп калдырырга;

4.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:

«17) муниципаль янгын сагы булдыру.».
4.1 пунктта 7)  пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 20 абзац өстәргә:

«20) шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге муниципаль районнар чикләрен янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итәргә;»

4 статьяның 8 пунктындагы беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

« - граждан хәле актларын теркәү буенча вәкаләтләрне 2005 елның 30 декабрендәге «ТР да җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге аша;

- опека һәм попечительлек буенча вәкаләтләр 2008 елның 20 мартындагы “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге аша;

- архив эше өлкәсендәге вәкаләтләрне 2004 елның 24 декабрендәге “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге аша;

- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтләрне 2006 елның 7 апрелендәге “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 29-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге аша;

- балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең эшчәнлеген оештыру өлкәсендәге вәкаләтләрне 2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның

эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә балигъ булмаганнарның эшләре һәм административ практика секторының баш белгече (балигъ булмаганнарның эшләре буенча комиссияләрнең җаваплы секретаре) йөзендә;

- административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру өлкәсендәге вәкаләтләр 2005 елның 30 декабрендәге “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторының административ комиссиясе җаваплы секретаре йөзендә.